ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26 12 2019 г. № 917

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләүне билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак Кодексының 14 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен торак урыннардан файдаланган өчен һәм Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен түләү күләмен расларга һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә һәм 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә дип санарга (кушымта).

2. Түбән Кама муниципаль районы үзенең гомуми җыелышында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның милекчеләре өчен 2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорга торак урынны карап тоту өчен түләү әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән күләмдә раслана.

3. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә торак урыны өчен түләү билгеләү турында» 2018 елның 26 декабрендәге 1080 номерлы карарын 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Г. Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 26-нчы декабрь
917-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы җирлекләрендә социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен һәм
Түбән Кама муниципаль районында күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларның торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны карап тоту өчен
2020 елның 1 гыйнварыннан 2020 елның 31 декабренә кадәр чорга түләү күләме

| т/с | Түләү исеме | Үлчәү берәмлеге | Түбән Кама шәһәре | Кама Аланы шәһәр тибындагы поселогы | Авыл җирлекләре | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Красный Ключ, Афанас | Каенлы, Иске Чишмә, Кызыл Чапчак, Түбән Уратма, Майская Горка, Шәңгәлче, Макаровка | Ширәмәт, Сухрау |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,47 | 3,29 | 3,47 | 2,10 | 1,09 |
| 2 | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,29 | 3,54 | 2,29 | 1,92 | 1,17 |
| 3 | Йорт яны территориясен җыештыру | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,42 | 2,28 | 2,42 | 2,92 | 1,66 |
| 4 | Чүп үткәргечкә хезмәт күрсәтү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,70 | 1,69 | - | - | - |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 5 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,96 | 2,72 | 2,96 | 2,71 | 2,56 |
| 6 | Йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,74 | 2,11 | 2,74 | 1,83 | 1,68 |
| 7 | Җылылык алмашу җиһазлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,01 | - | - | - | - |
| 8 | Йорт эчендәге үзәк җылыту челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 2,72 | 1,42 | 2,72 | - | 1,19*** |
| 9 | Йорт эчендәге электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,05 | 1,13 | 1,05 | 1,00 | 1,09 |
| 10 | Йорт эчендәге газ челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм агымдагы ремонт ясау | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,26 | - | 0,26 | 0,26 | 0,26 |
| 11 | Дератизацияләү (дезинсекцияләү) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,17 | 0,18* | 0,17 | 0,17 | 0,17 |
| 12 | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | сум./куб.м. | - | - | - | - | 33,33** |
| 13 | Наемга түләү (наемга алучыларга) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | Методика нигезендә дифференцияләнгән | | | | |
| 14 | Капиталь ремонт (милекчеләр өчен) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 6,11 | 6,11 | 6,11 | 6,11 | 6,11 |
| 15 | Лифтларга хезмәт күрсәтү | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 3,93 | 4,84 | - | - | - |
| 16 | Техник чараларга һәм янгын сүндерү һәм төтен суырту системаларына хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 1,03 | - | - | - | - |
| 17 | Чүп үткәргечсез күпфатирлы йортлар буенча чүп контейнерларын карап тоту (хезмәт күрсәтү булганда) | айга торак бинаның гомуми мәйданы сум/кв.м. | 0,19 | - | 0,19 | 0,19 | 0,19 |

Искәрмә:

*     тариф НДСны исәпкә алып билгеләнгән;
**    тариф Сухрау авыл җирлеге буенча билгеләнгән.
***   тариф Ширәмәт авыл җирлеге буенча билгеләнгән